

31 мартта Ромоданово районында илебез Президенты тарафыннан игъълан ителгән Россия халыкларынын мәдәни мирасы елына старт бирелде.
Ромоданово авылы мәдәният йорты сәхнәсендә «Халык рухы» дип исемләнгән халык жырынын этнокультура бәйрәме узды. Матур бизәлгән сәхнәгә рус, мордва, татар, халык жырларын башкаручы vзешчән артистлар чыгыш ясадылар.      Бу бәйрәмдә Алтар авылынын «Чишмә» ансамбле бик матур программасын тормышка ашырды. Үзенчәлекле мәдәният, гореф-гадәт-ләр, традицияләр - болар барысы да vзешчән коллективлар ижатында саклана, арта бара. Программа бик бай һәм кызыклы булган. Тамашачылар һәр чыгыш ясаучыны жылы сәламләделәр, озак алкышларга кvмделәр.